РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24 гыйнвар, 2017 ел № 3

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Түбән Кама шәһәр Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен карап тикшергәннән соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы муниципаль берәмлеге Түбән Кама шәһәр Уставы, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә (кушымта).
2. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.
3. Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшинга әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвен алу өчен җибәрергә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр Советының
2017 елның 24 гыйнвареннән
3 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. **«Шәһәрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә хокукы»** турындагы 7 статьясының 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 13нче пунктны өстәргә:

“13) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" Федераль законда каралган хокук бозуларны кисәтү өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру.».

2. **22 статьяда «Гавами тыңлаулар» 3 пунктының 1 пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, Уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (устав) яисә Россия Федерациясе субъекты законнарының әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында төгәл яңадан карау формасына үзгәрешләр кертү;».

3. **“Шәһәр Мэрының вәкаләтләре" турындагы 46 статьяны** түбәндәге эчтәлекле 18-20 пунктлар белән тулыландырырга:

“18 «Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә ачык партнер буларак чыгыш ясый.;

19) муниципаль-шәхси партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул итә;

20) «Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясындагы 2 өлеше нигезендә муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органын билгели.».

4. **47 статьяда “ Шәһәр Мэры урынбасарлары"** 4 пункт:

«вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату» сүзләреннән соң «яисә аны суд карары буенча сак астына алу, яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары куллану» сүзләрен өстәргә;

«гамәлгә ашыра» сүзен «вакытлыча башкара» сүзләренә алмаштырырга.

**5. «Шәһәр башкарма комитетының вәкаләтләре» 51 статьясында:**

а) 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5.14 пунктча өстәргә:

«5.14. билгеләнгән вәкаләтләр өлкәсендә инвалидларның социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектларына тоткарлыксыз керүен тәэмин итә;»;

б) 7 пунктка түбәндәге эчтәлекле 7.17 пунктча өстәргә:

«7.17. «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны кисәтү өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра.».

6. **“Шәһәр башкарма комитеты Җитәкчесе” 52 статьясында** 6 пунктта:

а)«гамәлгә ашыра» сүзен «вакытлыча башкара» сүзләренә алмаштырырга;

б) «вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату» сүзләреннән соң «яисә суд карары буенча сак астына алу яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чараларын куллану» сүзләрен өстәргә.

7. **«Шәһәр Уставы проектын әзерләү, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе»** 94 статьясында 3 пунктта «күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр шәһәр Уставын Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга туры китерү максатларында кертелсә.» сүзләрен «Уставка әлеге Уставны шушы норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (устав) яисә Россия Федерациясе субъекты законнары нигезләмәләрен төгәл торгызу рәвешендә үзгәрешләр кертелгәндә» сүзләренә алмаштырырга.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары Э.Р. Долотказина